# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлегенең Ләке авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**“14” ноябр 2020 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 14 ноябрендә 10.00 сәгатьтә, 2020 елның 14 ноябрендә 14.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2021 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; хәрби хезмәт үтүче гражданнардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

- Ләке авылы чишмәсен төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм төзелеш эшләре өчен түләү.
- Ләке авылында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру.
- Ләке авылы зират өчен сугу чүкече һәм генератор сатып алу;
- Ләке авылында җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту.
- Ләке торк пунктының урамнарын яктырту буенча өстәмә нокталар урнаштыру;
- МТЗ-82 тракторын карап тору (махсус техника өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу);
- Ләке авылы территориясен һәм юл буйларын чабу.
- Ләке авыл җирлегендә өлкәннәр һәм инвалидлар көне үткәрү өчен бүләк пакетлары алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 263 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 154 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 154катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлегенең Ләке авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.
2. «2021 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; хәрби хезмәт үтүче гражданнардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

- Ләке авылы чишмәсен төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм төзелеш эшләре өчен түләү.
- Ләке авылында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру.
- Ләке авылы зират өчен сугу чүкече һәм генератор сатып алу;
- Ләке авылында җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту.
- Ләке торк пунткының урамнарын яктырту буенча өстәмә нокталар урнаштыру;
- МТЗ-82 тракторын карап тору (махсус техника өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу);
- Ләке авылы территориясен һәм юл буйларын чабу.
- Ләке авыл җирлегендә өлкәннәр һәм инвалидлар көне үткәрү өчен бүләк пакетлары алу кабул ителде.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Ләке авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Л. И. Шәрипова